

ISSN 0868-4545

Сәләват күпере

Ал кулыңа каләм, дускай...

Җил малае Җилкәй агачлардан коелган сары-кызгылт яфраклар белән куышлы уйный. Аларның күңелле уенына көз малае Сентябрь килеп кушыла...

Бу – көз, алтын көз.

Алмагачларда ал, сары алмалар елмая, кып-кызыл баланнар йолдызлар күк җемелдәшә...

Бу – көз, көзнең иң гүзәл чагы. Шагыйрь әйтмешли:

Үтте-китте матур җәйләр,
Көзләр килеп җиттеләр...

Әйе, җәй артта калды. Көз килде. Синең күңелеңдә исә әле һаман җәй тантана итә: күпме күңелле хәлләрнең үзәгендә булдың син, шулай бит?! Шул хәлләр, кызыклы вакыйгалар әледән-әле синең исеңә төшә. Син алар турында дусларыңа сөйлисең, кызык-мызык җирләрендә бергәләп көлешәсез...

Йәле, дускай, үзең яисә дус-ишләрең белән булган шул күңелле, кызык, әкәмәт хәлләр турында язып җибәр әле безгә. Язмаңны шигъри калыпка салып (ягъни шигырь итеп) юлласаң да ярый.

Урамда – көз, күңелдә – җәй...
Ал кулыңа каләм, дускай...



Рәссам Диләрә НӘҮРҮЗОВА

© "Салават күпере", 2005 ел





Фәнис ЯРУЛЛИН

Көзге табын


Көзге табын – бай табын,
Кыяр, карбыз һәм кавын
Телем-телем теленгән,
Өем-өем өелгән.


Алмалары ал төсле,
Балкып туган таң төсле.
Капсаң эри авызда,
Һәр кисәге бал төсле.

Ә җимеше, җимеше,
Ачысы бар, төчесе!
Яңа пешкән күмәчтер
Кайнар кояш төслесе.

Әткәм кебек тырыш көз,
Әнкәм кебек юмарт көз.
Көзләр юмарт булганга,
Бик бәхетле, бик шат без.







Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН

«Әни» дип ачылган тел

Моннан бер ел элек Мансур абый бабай булды. Кызы Гүзәлнең улы туды. Исемен дә үзебезчә куйдылар. Артур да, Руслан да, Тимур да түгел, чын татарча Галимҗан дип атадылар. Хәзер инде Галимҗан биләүдән чыкты, бишектән дә төште. Идәндә мүкәләп йөри башлады. Тиздән аягына да басар, теле дә тәмам ачылыр. Әнә хәзер үк инде идәнгә уенчыкларын таратып ташлый да үзенчә сукалый.

Ә бер көнне... бер көнне өйдәгеләрнең барысын да гаҗәпкә калдырып, кулларын җәеп, әнисенә карап, алпан-тилпән атлап китте.

Моны күреп сөенгән әнисе:

– Ай, нинди дәү булган минем улым, кил әле яныма, кил әле... – диюенә каршы Галимҗан:

– Әни... – дип сөрән салды.

Бу хәлне күргәч, бабасы Мансур түзмәде, куанычыннан сикереп торды да оныгын кулларына алды. Югарыга күтәрде.

– Афәрин, улым! Телең үзебезчә, әни дип ачылды. Болай булгач, әйбәт, акыллы егет булып, милләтебезнең горурлыгы булып үсәрсең, иншалла. Тик берүк беркайчан да туган телеңне оныта күрмә, яме! – дип, үз итеп, оныгының бит алмаларыннан үбеп алды.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Рашат НИЗАМИ

Автобуслар... футбол уйный

Юк, сөйләмим мин әкият,
Сөйлимен күргәнемне.
Шәһәр урамнары буйлап
Зур атлап йөргәнемне.

Җәйләр эссе... Эчемлекнең
Күп төрлесен эчәсең.
Юл өстенә ташлаганнар
«Пепси – кола» шешәсе.

Пластмасс шушы шешәне, –
Ышанасызмы, дуслар, –
Әле уңга, әле сулга
Типкәли автобуслар!

Ничә тапкыр «Гол!» кергәнен
Хет дәфтәргә язып бар:
Узган шәпкә туп тибешә
«Газель»ләр һәм «ПАЗ»иклар.

Карап торышка күңелле,
Әллә начар инде без? –
Урамыбыз чисталыгын
Бер дә саклый белмибез...







Тәлгат абый мәзәкләре

Тәлгат абый Нәҗмиев Кукмара районының Байлангар авылында туган. Кечкенә чагында ук бик тырыш, тынгысыз, һәр эштә өлгер бала булган ул. Шундый булгангадыр, мөгаен, Кара диңгез буендагы «Бөркеткәй» Бөтенроссия пионерлар лагерына бару бәхете тигән үзенә...

Тәлгат абый бүген Сабада яши. Районда нәшер ителүче «Саба таңнары» гәҗитенең баш мөхәррире. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. «Саба мәзәкләре», «Тагын... Саба мәзәкләре», «Тагын... тагын... Саба мәзәкләре» дигән китаплар авторы.



«Медаль»



Матур табигатьле Түбән Симет авылына җәй саен Казаннан вундеркинд малай – Рөстәм кайтып ял итә торган була.

Тәрәзәдән күрше карчыгын – чулпытәңкәләрен ялтыратып-шалтыратып килгән Афзалниса түтине күреп ала да:

– Дәү әни, дәү әни, медальләрен тагып бер әби килә. Нәршә, ул шугышта булганмы әллә? – дип сораган.

Кыйбат әби

Улым Нияз кечкенә вакытта авылга кайткач, энем аңа хәйран зур бәягә ике тәгәрмәчле бик матур велосипед алып биргән. Бала аңламас, диптер инде, әни Зөфәрне «кыздырган», катькат:

– Кыйбат бит, кыйбат, ник алдың? – дигән.

Әлеге әңгәмәне тыңлап торган сабый яратмаган әбисенең бу гамәлен. Абыйсын кызганган. Шуннан соң «Кыйбат әби» дигән кушамат такты әбиенә: «Кая барасың?» – дип сорасалар, «Кыйбат әби»гә кайтам», – дия торган булды.

Бервакыт әбисе әкрен генә:

– Улым, бүтән алай димә, яме! – дип үтенә моңардан.

Бала кеше дә бирешергә теләми.

– Менә бу төш «әйт-әйт» дип тора бит, – дия-дия йөрәгенә төртеп күрсәтә.


Буялган сыер



Эзмә авылында Харис ага белән Кифая апаның шәһәрдәге оныклары кайтуга сыерларын алмаштырган булалар. Руслан «сөтлебикә»гә бик сәерсенеп карап тора да:

– Бабай, сыерны нишләттегез? Икенче төскә буягансыз бит! – дип үзенчә нәтиҗә ясап куя.

Ата-анасы булгач...



Руслан, беренче классны тәмамлап, җәйге каникулга кайта. Аңа олы ышаныч белдерелә – каз бәбкәләре сакларга кушып, ашарына төйнәп бирәләр.

Әмма Руслан озак тормый, әйләнеп кайтып җитә.

– Улым, нишләп бибиләрне ялгыз калдырдың? – дип сорый Харис бабасы.

– Ата-аналары бар, шулар карарлар әле, – дип җавап бирә ул.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Лилия Газизова шигырьләре



Керпеләр

Ике керпе бар бездә –
Бездә, дим, бакчабызда!

Ялкау малайлар кебек
Бер дә йоклап ятмыйлар:
Өебезне икәүләп
Тычканнардан саклыйлар!

Керпекәйләрем белән
Дуслашасым бик килә:
Үзләренә җыр җырлыйм,
Шигырь сөйлим – тик тормыйм.

Керпекәйләрнең генә
Исләре китми миңа.

Алайса җырламыйм, дим,
Шигырь сөйләмим, димен.
Дуслашуның җай-әмәлен
Инде беләмен, димен:

Керпеләремне гелән
Сыйлыйм әле сөт белән!





Рәссам Алла АЙСИНА

Озын санамыш

Бер, ике, өч...
Көн уянды ич!

Дүрт, биш, алты...
Көн безне дә уятты!

Җиде, сигез, тугыз...
Көннең эше бик тыгыз!

Тугыздан соң килә ун –
Көн үз эшен белә ул:
Шаулый, көлә йә җырлый –
Безнең кебек тик тормый!

Олыны да, кечене дә –
Барлык-барлык кешене дә
Үз итә ул, ярата –
Якты нурлар тарата.

Тылсымчы күк могҗизалар
Күрсәтә ул...
Кем дисең?
Әллә инде Көн икәнен
Син һаман да белмисең?!

Тагын – бер, тагын – ике...
Тагын – өч, дүрт, биш, алты...
Кичкә таба Көн арды –
Татлы йокыга талды.





– Җәйләр буе, көннәр буе
Трактордан төшмәдек:
Ашауларны да оныттык –
Эшләдек тә эшләдек.


Нурлат.






– Энекәш, син монда утыр,
Ә мин машина йөртәм.
Җырлап барып, төшеп калма,
Мин бик оста җилдертәм!


Әгерҗе, Исәнбай.







– Әбиемә булышыйм, дип
Тотындым май язарга.
Маем төшсә, алып китәм
Үзебезгә – Казанга.

Әгерҗе, Исәнбай.









– Үземә кәләш таптым
Балалар бакчасыннан:
Сайлап алдым иң шәбен
Күп кызлар арасыннан!


Азнакай.



Илнара, 1 яшь 2 ай

– Тәрәзә белән диванның
Бик тар болай арасы.
Кем уйлаган, шул арада
Ыштан төшеп каласын!

Башкортостан,
Чишмә, Сафар.



Дамир, 8 ай



– Уйнар идем туйганчы –
Күңелләрем булганчы...
Ятактан төшәлмим бит –
Тиз генә үсәлмим бит!

Пермь, Барда.


Нәзилә, 9 яшь
Таңсылу, 6 яшь



– Үстердек без кабаклар –
Барсы да зур табактай!
Дуслар күреп шаккатты –
Һәммәсе тел шартлатты!

Актаныш, Усы.


Алсу, 2 яшь

– Апамнан алдарак
Уяндым йокыдан,
Тиз генә барам да
Кайтам мин укудан!

Кайбыч, Кошман.



Резеда ШӘРИПОВА

Яшенле яңгыр

Бер тамчы,
Ике тамчы...
Уйнады яшен-камчы!
Ялтыр-йолтыр,
Шарт та шорт,
Исте җилләре тузгып,
Ачуланды бик яман,
Әйтерсен, ахырзаман!
Актылар гөрләвекләр,
Җыелды күлдәвекләр.
Дөбердәп котырынды,
Котырынды да – тынды.
Ялтырап кояш чыкты,
Күккә салават сызды.
Кара инде, гел юктан,
Шул яшеннән курыктым!



Сания ХӘСӘНОВА

Камилә

Бик кечкенә Камилә –
Үзе шаяра, көлә:
Юри бездән кача да
Уйнап йөри бакчада.

Тере курчак кебек ул –
Курчак кебек кечкенә.
Төннәрен җылап ала,
Әллә инде күзсенә...

Камилә, дим, Камилә,
Әйдә, тизрәк үс инде!
«Бер дә ашыкмыйм үсәргә,
Болай рәхәт», – дисеңме?!

Камилә бик кечкенә,
Кечкенә дә төш кенә...

Бигрәк рәхәт балачак –
Мин дә кызыгам кайчак!!!

Хак ШӘЙХИ

Минем дустым

Мин авылга кунак булып,
Еш кайтам үзе болай.
– Кайттыңмы? – дип, каршы ала
Капка төбендә бабай.

– Һау-һау, – диеп сәлам бирә
Миңа дустым Актүш тә,
Аннан янга чабып килә:
– Чык әйдә, – ди, – чәй эч тә!

Дүрт аяклы тугры дустым –
Онытмый ул, ят итми,
Шатлыгыннан кочып ала:
– Кайттыңмы, дус, уйныйк, – ди.

Мин юл тузаннарын каккач,
Без чабабыз урамга,
Яшел чирәмдә тәгәрәп,
Бер туйганчы уйнарга.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Тылсымлы малай ярдәме



Әкият


Борын-борын заманда бер әби белән бабай яшәгән. Аларның малае да, кызы да булмаган.

Әби белән бабайның ягарга утыннары беткән. Беркөнне бабай утынга киткән. Урманга барган да утын кисә башлаган. Шунда кинәт бер тавыш ишетелгән һәм агачлар арасыннан бер малай килеп чыккан. Бу – кеше түгел, ә урман иясенең улы икән. «Бабай, син карт инде. Ял итеп кенә утыр, үзем эшләрмен», – дигән малай. Ул бабайга күп итеп утын кисеп биргән дә, үзе юкка чыккан. Бабай рәхмәт әйтергә дә өлгерми калган. Шулай итеп бабай утынлы булган. Ә урман иясенең улы бүгенге көннәрдә дә урманда очраган ялгыз картларга ярдәм итә икән.

Зилә СӨЛӘЙМАНОВА, 8 яшь.
Актаныш, Богады.



*Ләйсән ШӘРИПОВА, 10 яшь.
Әлмәт.*



*Алсу ӘСЛӘМОВА, 10 яшь.
Әлмәт.*



*А.ГАТИЯТУЛЛИН, 9 яшь.
Баулы, Татар Кандызы.*



*А.МОРАТХУҖИНА, 9 яшь.
Баулы, Татар Кандызы.*



Алинә ЗАКИРОВА, 10 яшь.
Чистай, Уракчы.



Энҗе ЧАРЫШЕВА, 7 яшь.
Казан, 122 нче гимназия.



Аня ЕГИНА, 10 яшь.
Казан, 122 нче гимназия.



Илфир ҺИДИЯТУЛЛИН, 9 яшь.
Әтнә, Бәхтияр.

Авылыбыз табигате

Без — Азнакай районы Тымытык урта мәктәбенең 4 сыйныф укучылары. Үзебезнең туган авылыбыз турында берничә сүз әйтеп китәсебез килә.

Безнең авыл бик зур. Табигате дә бик күркәм. Авыл янында әрәмәләр, таулар бар. Болыннарның да чиге күренми. Кыш көне авылда бик күңелле була. Балалар хоккей уйныйлар, чана, чаңгы шуалар. Балалар гына түгел, олылар да, бала-чага кебек, беренче карны сагынып көтәләр, шатланалар. Кышның бит үзенең бер рәхәте бар. Салкын урамнан җып-җылы өйгә кайтып керүе генә дә ни тора. Яз көннәрендә авылда ташулар башлана. Һавада ниндидер тылсымлы ис сизелә – бу яз исе. Бөтен дөнья йокыдан уянган кебек була. Сыерчыклар килгәч, урамнар аларның җырлары белән тула. Җәй көннәрендә авылда эш вакыты. Бөтен авыл халкы кышка җиләк-җимеш, печән, утын әзерли. Ләкин авыл кешесе эштән курыкмый. Көзен инде авылда уңыш җыялар. Халык бәрәңге бакчаларына чыга, басуларда комбайннар шаулый.

Руслан СӘГЪДИЕВ, Миләүшә ХӘНИПОВА,
Эля ШӘЙХЕТДИНОВА, Разалия ШИҺАПОВА.





Ләбиб ЛЕРОН


Көтәбез

Без һәммәбез дә көтәбез.
Әти дөнья көтә.
Апам тәрәзәдән күзен алмый. Кемнедер көтә.
Беләм инде, беләм, күршебез Таһир абыйның безнең өй турысыннан үткәнен көтә.
Абый каникулны көтә. Каникулга чыккач, атлар көтәм, ди.
Әни мичкә бәлеш тыкты. Шуны көтә.
Ә мин? Мин шул бәлешнең пешкәнен көтәм.
Ә мине тышта балыкка барырга дип Айрат көтә. Көтсен. Мин көтәм ич...

Бәлеш пеште. Рәхәтләнеп сыйландым да урамга – Айрат янына чыктым. Чыксам... Айраттан җилләр искән!..

Көтә белмәгән кешеләргә исем китә минем.

Ә сезнең?



Рәссам
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Алсу алма

Баһадир, бакчага кереп, алмагачтагы бердәнбер алманы үрелеп алды да тәмләп ашый башлады...

– Тәмле! Искиткеч! – диде ул, башын чайкый-чайкый.

Аның ашаганын карап торган энесе Фәндәвис: «Абый кебек үскәч, мин дә үрелеп кенә алма алырмын әле!» – дип уйлады һәм төкереген йотып куйды.

– Тәмле булды бу! – диде Баһадир һәм алма чүбен алмагач төбенә ыргытты.

«Алманы үрелеп алгач, абый белән икәү әнә шулай тәмле итеп ашар идек», – дип уйлады Баһадирның энесе Фәндәвис һәм әле алмагачка, әле алма чүбенә карап алды.

– Тәмле булды ул алма! – диде янә Баһадир һәм, күлмәген өскәрәк күтәреп, эченә суккалады...

Алма чыннан да тәмле иде.



10 аерманы тап.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Сәләват күпере

9 (198) — 2006

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.

1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.

Основан в 1990 году.

На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта С.ИБРАҺИМОВА рәсеме

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы,2 нче йорт.

Производствога бирелде 1.09.2006 ел.

Басарга кул куелды 1.09.2006 ел.

Кәгазь форматы 84х108 1/16.

Гарнитура – Прагматика.

Офсет ысулы белән басыла.

Тираж 9993 данә. Заказ 3-748.

Санны әзерләүчеләр:

З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



Ләбиб ЛЕРОН

Яфрак бәйрәме

Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Көз турында мин җырлыймын –
Кушыл син яңа җырга:

Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак –
Көзнең матур чаклары.

Оча яфрак, уйный яфрак
Һаваларда әйләнеп.
Бүген, бүген, бүген, бүген
Яфракларның бәйрәме!